Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

05 сентябрь 2019 ел № 122

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә тәкъдим итәбез:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, ташламалы категориядән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада укучы студентлар), җирлек территориясендә тавыш бирергә хокуклы һәр гражданнан 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме?

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Осинники бистәсендә вак таш җәелгән юлны ремонтлау: Яшьләр урамы, Урман урамы;
- Осинники авылы зираты коймасын ремонтлау;

“ӘЙЕ” “ЮК”

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
- Осинники авылы, Яшьләр урамы, 9А йорт (административ бина);
- Осинники авылы, Лесная ур., 2 йорт (Осинник авыл мәдәният йорты),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Осинники
авыл җирлеге Советы рәисе А.Х. Сәгдиев